| | |
|---|---|
| **МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ** |

| | |
|---|---|
| **ПРИКАЗ** | **БОЕРЫК** |
| 12.02.2018 | № 109 |

Казан ш.

“Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының дәүләти гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр бәрелешен җайга салу буенча комиссиясе турында” 05.09.2016 ел, № 509 Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының дәүләти гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр бәрелешен җайга салу буенча комиссиясе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

“Коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында” 11 декабрь, 2017 ел, № УП-1092 Татарстан Республикасы Президенты Указы кабул ителүгә бәйле

рәвештә, б о е р ы к  б и р ә м:

“Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының дәүләти гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр бәрелешен җайга салу буенча комиссиясе турында” 05.09.2016 ел,  № 509 Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының дәүләти гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр бәрелешен җайга салу буенча комиссиясе турында нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 28.12.2016 ел, № 743 боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләре кертергә:

3.4.1 һәм 3.4.2 пунктлары нумерацияләрен $3.4^1$ һәм $3.4^2$ итеп үзгәртергә;

түбәндәге эчтәлектәге $3.4^3$ пунктын өстәргә:

“$3.4^3$. Бу Нигезләмәнең 3.4 һәм $3.4^1$ пунктларында күздә тотылган нигезле бәяләмәләр түбәндәге мәгълүматларны үз эченә алырга тиеш:

а) бу Нигезләмнең  3.1 пунктындагы «б» пунтчасының икенче һәм өченче абзацларында һәм «д» пунктчасында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрдә яки уведомлениеләрдә бәян ителгән мәгълүматны;

б) запрослар нигезендә дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм кызыксынулы оешмалардан алынган мәгълүматны;

в) бу Нигезләмәнең  3.1  пунктындагы «б» пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында һәм «д» пунктчасында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләр һәм уведомлениеләрне башлангыч карап тикшерү нәтиҗәләре буенча нигезле йомгакны һәм бу Нигезләмәнең  3.13, 3.15.1, 3.18 пунктлары нигезендә карарларның берсен яки башка карар кабул итү өчен тәкъдимнәрне.”.

Министр                                                                                     Э.Ә. Зарипова